КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 30 март г.Казань № 292

2022 елда җирле үзидарә органнарының ашыгыч хәбәр итү системаларына эксплуатацион-техник хезмәт күрсәтү өлешендә гадәттән тыш хәлләр турында халыкка хәбәр итүнең һәм мәгълүмат бирүнең муниципаль системаларын булдыру һәм аларның даими әзерлеген тәэмин итеп тору өлкәсендә вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен тулы күләмдә финанслашу өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2022 елда җирле үзидарә органнарының ашыгыч хәбәр итү системаларына эксплуатацион-техник хезмәт күрсәтү өлешендә гадәттән тыш хәлләр турында халыкка хәбәр итүнең һәм мәгълүмат бирүнең муниципаль системаларын булдыру һәм аларның даими әзерлеген тәэмин итеп тору өлкәсендә вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен тулы күләмдә финанслашу өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 30 март, 292 нче карары белән расланды

2022 елда җирле үзидарә органнарының ашыгыч хәбәр итү системаларына эксплуатацион-техник хезмәт күрсәтү өлешендә гадәттән тыш хәлләр турында халыкка хәбәр итүнең һәм мәгълүмат бирүнең муниципаль системаларын булдыру һәм аларның даими әзерлеген тәэмин итеп тору өлкәсендә вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен тулы күләмдә финанслашу өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе

1. Бу Тәртип 2022 елда җирле үзидарә органнарының ашыгыч хәбәр итү системаларына эксплуатацион-техник хезмәт күрсәтү өлешендә гадәттән тыш хәлләр турында халыкка хәбәр итүнең һәм мәгълүмат бирүнең муниципаль системаларын булдыру һәм аларның даими әзерлеген тәэмин итеп тору өлкәсендә вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен тулы күләмдә финанслашу өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү (алга таба – шул ук эзлеклелектә муниципаль берәмлекләр, башка бюджетара трансфертлар) механизмын, максатларын һәм шартларын билгели.

2. Башка бюджетара трансфертлар бу Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен акча белән баш эш итүче буларак Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына (алга таба – Министрлык) билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм бюджет ассигнованиеләре чикләрендә бирелә.

3. Финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып башка бюджетара трансфертлар торган чыгымнар юнәлеше – юридик затларның (индивидуаль эшмәкәрләрнең) ашыгыч хәбәр итү системаларына эксплуатацион-техник хезмәт күрсәтү буенча башкарылган хезмәтләре өчен түләү.

4. Башка бюджетара трансфертларны муниципаль берәмлек бюджетына бирү шартлары:

ашыгыч хәбәр итү системаларына эксплуатацион-техник хезмәт күрсәтү чаралары исемлеген раслый торган һәм бу Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен башка бюджетара трансфертларны тоту тәртибе карала торган муниципаль хокукый акт булу;

муниципаль берәмлек бюджетында (муниципаль берәмлек бюджетының җыелма бюджет исемлегендә) Татарстан Республикасы бюджетыннан бирергә планлаштырыла торган башка бюджетара трансфертларны үз эченә алган чаралар исемлеген гамәлгә ашыру буенча муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләрен үтәүгә бюджет ассигнованиеләре булу;

финанслашу максатларында башка бюджетара трансфертлар бирелә торган чыгым йөкләмәләрен үтәү буенча муниципаль берәмлек йөкләмәсе күздә тотыла

торган башка бюджетара трансфертлар бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзү һәм килешүдә каралган йөкләмәләрне үтәмәгән өчен җаваплылык.

5. Башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткече (алга таба – нәтиҗәлелек күрсәткече) – юридик затлар (индивидуаль эшмәкәрләр) тарафыннан ашыгыч хәбәр итү системаларына эксплуатацион-техник хезмәт күрсәтү буенча хезмәтләр күрсәтүгә төзелгән муниципаль контрактны (шартнамәне) 100 процент үтәү.

6. Башка бюджетара трансфертлар алу өчен муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы Министрлыкка түбәндәгеләрне кертә:

башка бюджетара трансфертларга ихтыяҗны финанс-икътисадый нигезләү теркәлгән, ирекле формада язылган башка бюджетара трансферт бирү турында заявка (алга таба – заявка);

муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы карарыннан вәкаләтле зат тарафыннан расланган һәм муниципаль берәмлек бюджетында Татарстан Республикасы бюджетыннан бирергә планлаштырыла торган башка бюджетара трансфертларны үз эченә алган чаралар исемлеген тормышка ашыру буенча муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләрен үтәүгә бюджет ассигнованиеләре булуны раслый торган агымдагы финанс елына муниципаль берәмлек бюджеты (җыелма бюджет исемлеге) турында өземтә;

бу Тәртипнең 4 пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән муниципаль хокукый акт күчермәсен;

юридик затлар (индивидуаль эшмәкәрләр) тарафыннан ашыгыч хәбәр итү системаларына эксплуатацион-техник хезмәт күрсәтү буенча хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль контрактларның (шартнамәләрнең) күчермәләрен.

7. Министрлык:

заявканы кергән көнендә теркәүгә ала;

заявка теркәлгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә бу Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән документларны карап тикшерә һәм башка бюджетара трансфертлар бирү турында яки башка бюджетара трансфертлар бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

8. Башка бюджетара трансфертлар бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

бу Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән башка бюджетара трансфертлар бирү шартларының үтәлмәве;

бу Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

бу Тәртипнең 6 пунктында каралган документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы.

9. i-муниципаль берәмлек бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертның күләме ($T_i$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$T_i = 2\,801{,}2 \text{ рубля} \times C_i \times 12,$$

монда:

2 801,2 сум – 1 айга тавыш-сирена белән хәбәр итү җайланмаларына техник хезмәт күрсәтүнең иң чик кыйммәте;

$C_i$ – бу Тәртипнең кушымтасы нигезендә i-муниципаль берәмлектә техник хезмәт күрсәтелергә тиешле тавыш-сирена белән хәбәр итү җайланмалары саны, берәмлек;

12 – техник хезмәт күрсәтү айлары саны.

10. Башка бюджетара трансфертлар бирүдән баш тарту сәбәпләре күрсәтелгән башка бюджетара трансфертлар бирүдән баш тарту турындагы хәбәрнамә Министрлык тарафыннан заявка теркәлгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органына җибәрелә.

11. Муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы бу Тәртиптә билгеләнгән таләпләрне үтәү шарты белән башка бюджетара трансфертлар бирүдән баш тарту турында хәбәрнамә алынган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә яңадан заявка бирергә хокуклы.

12. Башка бюджетара трансфертлар Министрлык белән муниципаль берәмлек арасында Министрлык тарафыннан башка бюджетара трансфертлар бирү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча төзелә торган килешү нигезендә бирелә.

13. Килешүдә түбәндәгеләр карала:

башка бюджетара трансфертларның максатчан билгеләнеше;

бирелә торган башка бюджетара трансфертлар күләме;

нәтиҗәлелек күрсәткеченең мәгънәсе;

башка бюджетара трансфертларны күчерү тәртибе һәм сроклары;

муниципаль берәмлек бюджетының финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып башка бюджетара трансфертлар торган чыгымнарын гамәлгә ашыру турында һәм нәтиҗәлелек күрсәткеченең ирешелгән мәгънәсе турында хисаплар бирү сроклары һәм формалары;

нәтиҗәлелек күрсәткеченең билгеләнгән мәгнәсенә ирешмәү нәтиҗәләре;

муниципаль берәмлек тарафыннан килешүдә каралган башка бюджетара трансфертлардан файдалану йөкләмәләренең үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибе;

килешү шартларын бозган өчен якларның җаваплылыгы.

14. Башка бюджетара трансфертлар Министрлык тарафыннан муниципаль берәмлек бюджетына килешү төзелгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениесендә муниципаль берәмлекләр бюджетлары акчасы белән операцияләрне исәпкә алу өчен ачылган Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенә караган территориаль орган счетына күчерелә.

15. Муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы 2023 елның 20 гыйнварына муниципаль район бюджетының финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып башка бюджетара трансфертлар торган чыгымнарын гамәлгә ашыру турындагы һәм нәтиҗәлелек күрсәткеченең ирешелгән мәгънәсе турындагы хисапларны килешүдә каралган тәртип һәм форма нигезендә Министрлыкка тапшыра.

16. Муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы бу Тәртипнең 15 пункты нигезендә тапшырыла торган хисапларның дөрес булмавы һәм башка бюджетара

трансфертлардан максатчан файдаланылмавы өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап бирә.

17. 2023 елның 1 гыйнвары хәленә карата файдаланылмаган башка бюджетара трансфертлар 2023 елның беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Башка бюджетара трансфертларның файдаланылмый калган өлеше Татарстан Республикасы бюджеты керемәнә күчерелмәгән очракта, әлеге акча, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне үтәп, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә Татарстан Республикасы бюджеты керемәнә түләтелергә тиеш.

18. Министрлык һәм дәүләт финанс тикшерүе органнары бу Тәртип һәм килешү белән билгеләнгән башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыра.

Контроль чаралар үткәрү барышында ачыкланган бозулар булган очракта, башка бюджетара трансфертлар муниципаль берәмлек бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына тулы күләмдә кайтарылырга тиеш.

19. Муниципаль берәмлек тарафыннан хисапларны бирү шартлары бозылган очракта, шулай ук муниципаль берәмлек тарафыннан бу Тәртипнең 16 һәм 17 пунктлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетына акча кире кайтарылмаган очракта, аңа карата Россия Федерациясенең бюджет законнарында каралган мәҗбүр итү чаралары кулланыла.

Башка бюджетара трансферлардан максатчан файдаланмау Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган акча суммасын законнар белән билгеләнгән тәртиптә бәхәссез түләтүгә китерә.

20. Башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2022 елда җирле үзидарә органнарының ашыгыч хәбәр итү системаларына эксплуатацион-техник хезмәт күрсәтү өлешендә гадәттән тыш хәлләр турында халыкка хәбәр итүнең һәм мәгълүмат бирүнең муниципаль системаларын булдыру һәм аларның даими әзерлеген тәэмин итеп тору өлкәсендә вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен тулы күләмдә финанслашу өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә кушымта

Техник хезмәт күрсәтелергә тиешле
тавыш-сирена белән хәбәр итү җайланмалары
исемлеге

| Т/с | Муниципаль берәмлек исеме | Тавыш-сирена белән хәбәр итү җайланмалары саны, берәмлек |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Әгерҗе муниципаль районы | 1 |
| 2. | Азнакай муниципаль районы | 1 |
| 3. | Аксубай муниципаль районы | 1 |
| 4. | Актаныш муниципаль районы | 1 |
| 5. | Алексеевск муниципаль районы | 1 |
| 6. | Әлки муниципаль районы | 1 |
| 7. | Әлмәт муниципаль районы | 1 |
| 8. | Апас муниципаль районы | 6 |
| 9. | Арча муниципаль районы | 2 |
| 10. | Әтнә муниципаль районы | 1 |
| 11. | Баулы муниципаль районы | 1 |
| 12. | Балтач муниципаль районы | 1 |
| 13. | Бөгелмә муниципаль районы | 1 |
| 14. | Буа муниципаль районы | 1 |
| 15. | Югары Ослан муниципаль районы | 1 |
| 16. | Биектау муниципаль районы | 1 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 17. | Чүпрәле муниципаль районы | 1 |
| 18. | Алабуга муниципаль районы | 4 |
| 19. | Зәй муниципаль районы | 1 |
| 20. | Зеленодольск муниципаль районы | 1 |
| 21. | Кайбыч муниципаль районы | 1 |
| 22. | Кама Тамагы муниципаль районы | 1 |
| 23. | Кукмара муниципаль районы | 1 |
| 24. | Лаеш муниципаль районы | 1 |
| 25. | Лениногорск муниципаль районы | 1 |
| 26. | Мамадыш муниципаль районы | 1 |
| 27. | Менделеевск муниципаль районы | 1 |
| 28. | Минзәлә муниципаль районы | 1 |
| 29. | Мөслим муниципаль районы | 1 |
| 30. | Түбән Кама муниципаль районы | 1 |
| 31. | Яңа Чишмә муниципаль районы | 1 |
| 32. | Нурлат муниципаль районы | 1 |
| 33. | Питрәч муниципаль районы | 3 |
| 34. | Балык Бистәсе муниципаль районы | 1 |
| 35. | Саба муниципаль районы | 3 |
| 36. | Сарман муниципаль районы | 1 |
| 37. | Спас муниципаль районы | 1 |
| 38. | Тәтеш муниципаль районы | 1 |
| 39. | Тукай муниципаль районы | 1 |
| 40. | Теләче муниципаль районы | 1 |
| 41. | Чирмешән муниципаль районы | 1 |
| 42. | Чистай муниципаль районы | 1 |
| 43. | Ютазы муниципаль районы | 1 |
| 44. | Яр Чаллы шәһәре | 1 |
| Барлыгы | | 57 |